*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре**
**2023-2024 нче уку елы**
**6 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 56**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Кече тел тартыгын билгеләгез. **(2 балл)**
1) [х]
2) [т]
3) [һ]
4) [ф]

2. Авазлар һәм хәрефләр саны туры килмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) алъяпкыч
2) юрган
3) йорт
4) вакыйга

3. Калын сузыклардан гына торган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**
1) Һәр эшнең ахырын уйла.
2) Бергә эшләсәң, авыр эш тә җиңел.
3) Дуслык - зур байлык.
4) Ил эче – алтын бишек.

4. Басымы соңгы иҗеккә төшкән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) күренмәдегез
2) татарча
3) язмыйбыз
4) укучылар

5. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Бизәкләп эшләнгән, җиңел, сай түгәрәк ир-ат баш киеме.*
1) эшләпә
2) бүрек
3) түбәтәй
4) башлык

6. Мәкальнең дәвамын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Дөньяда иң йомшак нәрсә* -
1) яңа яуган кар.
2) әнием кулы.
3) ак мамык.
4) үзең эшләгән мендәр.

7. Җөмләдәге фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
*Безнең Кәрим бик башлы булып чыкты.* (З.Бәшири)
1) булдыклы
2) эшчән
3) белемле
4) тырыш

8. Җөмләдәге омонимның төрен билгеләгез.
*Кара, төньяктан кара болыт килә*.
1) саф
2) омоформа
3) омографлар
4) омофон

9. Җөмләдәге сыйфатларның дәрәҗәсен билгеләгез. **(2 балл)**
*Дөньяда иң ачы нәрсә дә – тел, иң татлы нәрсә дә – тел*. (Мәкаль)
1) гади
2) чагыштыру
3) артыклык
4) кимлек

10. *Мин базардан карбыз, кавын һәм кыяр сатып алдым* җөмләсендәге ия белән хәбәрнең сүз төркемнәрен билгеләгез. **(2 балл)**
1) ия – исем, хәбәр – фигыль
2) ия – алмашлык, хәбәр – фигыль
3) ия – сан, хәбәр – исем
4) ия – сыйфат, хәбәр – фигыль

## II. Теоретик бирем.

Сан сүз төркеме, аның төркемчәләре турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. (**5 балл**)

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Сүз һәм авазларны тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) ал...япкыч | 1) һ |

| | |
|---|---|
| Ә) мә...ге | 2) а |
| Б) җәү...әр | 3) ң |
| В) к...нәфер | 4) ә |
| Г) җ...мәгать | 5) ъ |

**Җавап : ___________________________**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(4 балл)**

Безгә аклы-сарылы песи баласы кереп (урнашты / җитте / ияләште). Безнең үзебезнең бер песиебез бар иде инде. Ул песиебез үзе ап-ак, маңгаенда кара тап бар. Без аны матурлыгы өчен генә түгел, акыллылыгы өчен дә яратабыз. Ул, үзе бик (шаян / тәртипле / тыңлаучан) булса да, ашамлыкка тими. Күршеләргә дә кереп йөрми. Ә күршедән кергән песи бик тәртипсез булып чыкты. Бертуктаусыз «мияу-мияу» ди. Ашарга бирсәң, төрле җиргә тарата башлый да идәнне (буйый / пычрата / ямьсезли). Өстәлгә менеп, икмәк сыныкларын тартып төшерә. Тагын әллә нинди тәртипсезлекләр эшли. Беркөнне минем белән уйнарга иптәш кызым Мәйсәрә керде. Ул:

— Бу юньсез песине нигә керттегез? Ул инде бик күп кешегә йөрде. Бездә дә булды. Аны (гаять / бөтен / әллә) кеше дә куып чыгарды. Ул — акылсыз, сөйкемсез песи,— диде. (*Ә. Бикчәнтәевадан*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)**

Уйламыйча дустым бер сүз әйтте,
Ул сүз йөрәгемә ка....алды.
Үзе берни белми китеп барды.
Ә сүз калды.

Ул сүз тора минем йөрәгемдә
(А....нан авыр яра юк сыман).
Җә...сеннән ...лгыш атылып киткән
Һәм дустына тигән ук сыман.

(*И. Юзеев*)

3. *Калды* сүзен мәгънәви кисәкләргә таркатыгыз, нинди сүз төркеменә каравын, төрләнешен билгеләгез. **(4 балл)**

______________________________________________________________

______________________________________________________________

5.Шигырьнең икенче куплетыннан исем сүз төркеменә караган сүзләрне күчереп языгыз. **(6 балл)**

6. “Нәни дусларыбыз ярдәм көтә” темасына 8-9 җөмләдән торган инша языгыз. **(10 балл)**